**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Бохарай авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№63** **«24» ноябрь 2022 ел.**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен хезмәт хакы түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмә хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 87 номерлы Бохарай авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2013 елның 02 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен хезмәт хакы түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмә хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 87 номерлы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына (2018 елның 01 июньдэге 90, от 20.11.2018 елның№110, от 30.11.2018 №114, 2020 елның 22 сентябрендәге 5, 2021 елның 29 декабрендәге 38, 2022 елның 30 сентябрендәге 60 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен хезмәт хакы түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта:

2 пунктчада «(катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 8 пунктчаны өстәргә:

«8) нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләве.

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.6. Муниципаль хезмәткәркә хезмәт хакының 18 проценты күләмендә айлык акчалата түләү карала, җирле үзидарә органнары структурасын җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертүгә бәйле рәвештә үзгәртеп корганда муниципаль хезмәткәрне элегрәк биләгән хезмәт оклады азрак булган муниципаль хезмәт вазыйфасына күчергәндә акчалата түләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата түләү күләмен элек ул биләгән вазыйфа буенча акча күләменә җиткерүне тәэмин итеп, башкарылу очракларыннан тыш.

Муниципаль хезмәткәркә нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен вазыйфаи окладның 2 процентыннан да артмаган күләмдә айлык компенсация түләнә";

2.14 пунктта «11958 сум» сүзләрен «12688 сум» сүзләренә алмаштырырга;

2.15 пунктның 3 пунктчасында "ике процент" сүзләрен "15 процент" сүзләренә алмаштырырга, "вазыйфаи оклад" сүзләреннән соң ", җирле үзидарә органнары структурасын җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертүгә бәйле рәвештә үзгәртеп корганда муниципаль хезмәткәрне элегрәк биләгән хезмәт окладды азрак булган муниципаль хезмәт вазыйфасына күчергәндә акчалата түләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата түләү күләмен элек ул биләгән вазыйфа буенча акча күләменә җиткерүне тәэмин итеп, башкарылу очракларыннан тыш" сүзләрен өстәргә.

1.2. Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен хезмәт хакы түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмәгә 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бохарай авыл җирлеге башлыгы хезмәтенә түләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 17 390 |

».

2. Карарны торак пунктлар территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә локаль актларны әлеге нигезләмәгә туры китерергә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге**
**башлыгы** **Е.В. Груздева**